Гәрәй Рәхим

Казан
Татарстан китап нәшрияты
1981



ТУГАН ЯГЫМ

Кавказ кебек булмаса да, тауларың бар,
Каспий кебек булмаса да, суларың бар,
Тайга кебек булмаса да, урманың бар,
Мул уңышлар вәгъдә иткән кырларың бар,
Үзеңә хас матур-матур җырларың бар.

КЫЗЫЛ

Кызарып пешсен гел алмалар,
Бакчалар кып-кызыл булсыннар.
Тик менә кызарып янмасын
Авыллар, шәһәрләр, бу кырлар.

Кызарып чыксын гел кояш та,
Кызарып баесын кич белән.
Тик менә кызартып үләнне
Таммасын кан гына кешедән.

Бәйрәмдә һәркемнең мичендә
Кызарып бәлешләр пешсеннәр.
Тик менә хурлыклы мичләрдә
Янмасын, янмасын кешеләр.

БАЛАЛАР ҖЫРЫ БУ

Уйнасын быргылар,
Тынмасын барабан.
Кушылсын бу җырга
Җирдә бар балалар.

Әтиләр турында,
Әниләр турында,
Үзебез турында
Балалар җыры бу.

Җирнең чын уллары
Җыр белән көчләләр,
Кушылсын бу җырга
Иң гади кешеләр.

Азатлык турында,
Тынычлык турында,
Чын дуслык турында
Балалар җыры бу.

Җырласын мәйданнар,
Җырласын зур дәрья.
Бүгенге шат җырга
Кушылсын бар дөнья.

Табигать турында,
Кешеләр турында,
Бар дөнья турында
Балалар җыры бу.

ЯЗГЫ ӘКИЯТ

Түбәләрдән тып-тып тамчы тама,
Мин шатланып учны куям аңа.
Мин учымда яз җылысын тоям —
Мин бит шулай яз җылысын җыям.

Тал башында бер сыерчык сайрый,
«Шыгырт-шыгырт» итеп тешен кайрый.
Мин ул талга колагымны куям —
Мин бит шулай яз тавышын җыям.

Гөрләвектә кояш нуры уйный,
Елтыр-елтыр килә, бер дә туймый.
Гөрләвектән күзне алмый торам —
Мин бит шулай яз төсләрен җыям.

Кышкы салкын, шыксыз көннәр җиткәч,
Иптәшләрем кыштан туеп беткәч,
«Күңелсезләнмәгез!» — диярмен мин
Һәм язгы саф әкият сөйләрмен мин.

ТАКЫЯЛАР

Үрдем мин бик күп такыя
Ак чәчәкләр,
Күк чәчәкләр,
Күп чәчәкләр җыя-җыя.

Әни дә такыя кисен,
Әти дә такыя кисен.
Аларны күргән кешеләр:
— Әл-лә-лә-лә матур,— дисен.

Тагын үрдем күп такыя
Ал чәчәкләр,
Гөл чәчәкләр,
Гел чәчәкләр җыя-җыя.

Зурлар да такыя кисен,
Дуслар да такыя кисен.
Такыя күргән кешеләр:
— Әл-лә-лә-лә матур,— дисен.

Үрегез сез дә такыя
Ал чәчәкләр,
Гөл чәчәкләр,
Ак чәчәкләр,
Күк чәчәкләр,
Күп чәчәкләр җыя-җыя.

Бар илләр такыя кисен,
Бар җирләр такыя кисен.
Марсианнар күрсә безне:
— Әл-лә-лә Җир матур,— дисен,—
Әл-лә-лә-лә матур,— дисен.

ЯҢГЫРДАН СОҢ

Юлда ат тоягы эзенә
Кай ара су тулып өлгергән.
Ак каен яшел шәл ябынып
Бизәнә карап шул көзгедән.

Тамчылар кояшта ялтырап
Яфрактан яфракка сикерә.
Бөҗәкләр дип белеп аларны
Бер песнәк кабарга итенә.

Ә җирдә күбәләк аптырый,
Нигә, ди, авыр бу уң канат.
Белми шул, канаты өстенә
Бер тамчы тамызды кузгалак.

Ромашка кояштан көнләшеп
Киереп ача да таҗларын:
— Ягез,— ди,— күрегез, карагыз,
Кояштан ким минем кай ягым?!

ЯКТЫ АЛАНДА

Урмандагы якты бер аланда
Ял итәбез бергә җәй саен.
Җырлый-җырлый каршы ала
безне
Алан уртасында ак каен.

Җәй буена каен тирәсендә
Гөрләп тора көләч тавышлар.
Туган якны мактап җырлаганда,
Кушылалар безгә бар кошлар.

Каен башындагы кызыл әләм
Балкып торсын шулай ел саен.
Көннәр якты, яшәү якты булсын,
Гел соклансын безгә ак каен.

МӘКТӘПТӘН КАЙТКАН ЧАКТА

Безне күргәч кояш көлә,
Шатлануны ул да белә,
Арттан ияреп үк килә
Мәктәптән кайткан чакта.

Мәктәптән кайткан чакта,
Тукталып һәрбер чатта
Көлә-көлә сөйлибез,
Бишле алдык без, дибез.

Безне күргәч бөтен кеше
Бишлеләрне күрү өчен
Читкә куеп тора эшен —
Мәктәптән кайткан чакта.

Мәктәптән кайткан чакта,
Тукталып һәрбер чатта
Көлә-көлә сөйлибез,
Бишле алдык без, дибез.

Безне күргәч бөтен дөнья
Коенгандай була нурга,
Кошлар да кушыла җырга —
Мәктәптән кайткан чакта.

Мәктәптән кайткан чакта,
Тукталып һәрбер чатта
Җырлыйбыз көлә-көлә:
«Бишле алдык бүген дә».

ТӘНӘФЕС

Без дәрестә Ай өстендә йөрибез,
Котыпларда кала безнең эзебез.
Диңгезләрдә узган чакта зур сынау
Чылтыр-чылтыр чылтырыйдыр
кыңгырау.

Килеп җитте тәнәфес, тәнәфес,
Көтеп алган тәнәфес.
Биеп калыйк,
Җырлап калыйк,
Уйнап калыйк, әйдәгез.

Без дәрестә зур тауларны кичәбез,
Серләр эзләп җир астына төшәбез.
Упкыннарны үткән чакта тын гына
Чылтыр-чылтыр чылтырыйдыр
кыңгырау.

Килеп җитте тәнәфес, тәнәфес,
Көтеп алган тәнәфес.
Биеп калыйк,
Җырлап калыйк,
Уйнап калыйк, әйдәгез.

Без дәрестә ясыйбыз зур ачышлар,
Шундый кызык була безнең очышлар.
Күз алдына килеп баскач серле тау,
Чылтыр-чылтыр чылтырыйдыр
кыңгырау.

Килеп җитте тәнәфес, тәнәфес,
Көтеп алган тәнәфес.
Биеп калыйк,
Җырлап калыйк,
Уйнап калыйк, әйдәгез.



БЕР ЯЛГЫШУ — МЕҢ ЯЛГЫШУ

(Котыпчы турында баллада)

1

Әгәр шундый сорау бирсәм:
«Көньяк кайсы якта? — дисәм,—
Яки төньяк кайда?» — дисәм,
Көләрсең генә, бәлки.
Моннан да җиңел сорау юк,
Диярсең миңа, бәлки.

Син шул әле белмисеңдер
Ташавыл Әрчүгенең
Моннан унбиш еллар элек
Нәрсәләр кичерүен.

Бер ялгышу — мең ялгышу,
Дип дөрес әйткән халык.
Хур була язды бит Әрчүк
Әкәмәт хәлгә калып.

2

Әрчүк үзе әйбәт малай,
Беркайчан да шукланмый.
Дәресне тыңлап утыра,
Үзсүзләнми, мутланмый.

Лəкин шушы шəп малай да
Бер мəртəбə ялгышкан —
Дəрес тыңлап утырмаган,
Игътибары карышкан.

Укытучы өйрəткəндə
Көньякны һəм төньякны,
Йоклап ук утырган Әрчүк
Һəм бутаган бар якны.

Бер ялгышу — мең ялгышу,
Дип дөрес əйткəн халык —
Шушы көннəн үзсүзлелек
Килгəн Әрчүкне табып.

3

«Бу төньяк!» — дип күрсəткəн ул
Авылның көньягына.
«Монсы көньяк!» — дип күрсəткəн
Карап төньяк ягына.

Иптəшлəре көлгəн аннан,
Тик Әрчүк үзсүзлəнгəн.
«Үзем барып күреп кайтам
Көньякны»,— дип сөйлəнгəн.

Шул көнне үк ерак юлга
Дип чыккан безнең Әрчүк.
Көньякка дип төньягына
Юл тоткан безнең Әрчүк.

4

Өстə майка һəм шорт кына,
Башта салам эшлəпə.
Яланаяк атлый Әрчүк —
Күр, үзсүзлек нишлəтə.

Әй ашкынып бара Әрчүк
Җылы якка дип белеп.
Хыялында зур пальмалар,
Тропикларны күреп.

Поездга да утырган ул,
Самолетта да очкан.
Атлар җигеп,
Болан җигеп,
Этләр җигеп тә чапкан.

Ак аюлар аны күреп
Бии-бии көлгәннәр:
«Күрегез, күр, ул якларны
Бутаган бит»,— дигәннәр.

Тюленьнәр дә, моржлар да
Һәм төньяк көртлекләре,
Көмеш төлке, ап-ак кешләр,
Зур-зур кош көтүләре

Төрле тавышлар чыгарып
Көлгәннәр ди Әрчүктән.
Кире малайны күрергә
Килгәннәр ди һәр төштән.

5

Ләкин Әрчүк үзсүзләнгән,
Гел алга табан үткән.
Бер вертолетка элэгеп
Котыпка барып җиткән.

Ә Әрчүкнең өс киеме
Майка белән шорт икән.
Шорт белән килеп утыргач
Котып бозы «шарт» иткән,
Буйлап ярылып киткән.

Гаҗәпләнгән Әрчүк, монда
Пальма да юк, банан да.
Тик шулай да сер бирмәгән,
Үзсүзләнгән һаман да:

Теше тешкә тимәсә дә,
Үзенекен сөйләгән,
Әйтерсең ул калтыранып
Ниндидер көй көйләгән:
«Бар-р-р-ыбер-р-р табар-р-р-мын,— дигән,—
Кар-р-р-амам җил-дав-в-в-ылга.
Ә хәз-з-з-ергә туң-ң-ң-ам,— дигән,—
Кайтар-р-р-ыгыз ав-в-в-ылга!»

6

Бер ялгышу — мең ялгышу,
Дип дөрес әйткән халык.
Ташавылга кайтты Әрчүк
Тәмам көлкегә калып.

Ләкин Әрчүк кайту белән
Үз ялгышын төзәтте.
Үзсүзлеген җиңеп чыкты,
Начар холкын үзгәртте.

Биш бармагы кебек бишле
Ташыды ул дәрестән.
Зур бер галим өйрәнгәндәй
Өйрәнде ул Җир өстен.

Хәзер Әрчүк, беләсезме,
Кем булып үсеп чыкты?!
Ул — илдә Хезмәт Герое,
Ул — алдынгы котыпчы!

7

Әгәр шундый сорау бирсәм:
«Көньяк кайсы якта? — дисәм,—
Яки төньяк кайда?» — дисәм,
Көлмәссең инде, бәлки.
Моннан да җиңел сорау юк,
Димәссең инде, бәлки.

Бер ялгышу — мең ялгышу...
Бер дә ялгышма, дустым.
Яки төзәт ялгышыңны,
Озак карышма, дустым.

Бер ялгышу — мең ялгышу
Дисә дә бездә халык —
Төзәтеп була ялгышны,
Үзеңдә зур көч табып.

КӨЗ ЙӨРИ

Каурыйларда көз көйләрен уйнап.
Агачларны сары төскә буяп,
Куакларга җиләк-җимеш элеп,
Агач төпләренә гөмбә тезеп,
Урман буйлап алтын көз йөри.

Көшел-көшел бодай, арыш җыеп,
Саламнардан зур эскертләр куеп,
Кара җирне уҗым белән каплап,
Тракторлар белән гөрләп, шаулап,
Кырлар буйлап уңган көз йөри.

Безне җылы мәктәпләргә дәшеп,
Аяк асларына яфрак чәчеп,
Тәрәзләрне яңгыр белән юып,
Күп кошларны җылы якка куып,
Урам буйлап наян көз йөри.

КӨЗГЕ УРМАН

Ябалак кар яуган төсле
Яфрак ява кыштыр-кыштыр.
Гүя урман икеләнә:
«Көз түгелдер, кыштыр, кыштыр?!»

Просеклар туры-туры —
Алар урман коридоры.
Юлга калын палас җәя
Яфракларның саргылт хоры.

Миләш кызылга төренгән —
Яфрак кызыл, тәлгәш кызыл.
Каен сарыдан киенгән —
Урман күрке, урман кызы.

Тымызык җил исеп уза,
«Көзге урман» көен суза.
Баланнардан муенсалар
Аланнарга коелганнар.

Песнәк оча, ул ашыга
Тизрәк авылга кайтырга.
Көзен киткән кошлар өчен
Авыл ямен баетырга.

БУЯН ҺӘМ КУЯН

Куян бигрәк дус икән
Буян дигән ат белән.
Әй, уйныйлар,
уйныйлар,
Бер дә уйнап
туймыйлар.
Буян посып утыра,
Куян сагалап тора.
Буян сикереп чыга,
Куян тибеп очыра.
Буян кешни —
шатланган,
Ул Куянга атланган.
Бар дөньяны бетереп
Уйныйлар ду китереп.
Куян атны дус иткән,
Ат Куянны дус иткән.
Нигә дус булмасыннар,
Буяннар, куянчыклар —
Алар бит уенчыклар.

САЕСКАН ӨЙРӘТӘМ

Тәрәзәм каршысында,
Кунып казык башына,
И тыкылдый идең син,
Мине үртәп, юкны-барны
И лыгырдый идең син.
Миңа дәрес каратмыйча
И үчекли идең син,
Һич тә китми идең син.

Интектергәч бик озак,
Мин сиңа кордым тозак.
Очып килдең таллыктан —
Һәм... эләктең, саескан.

Менә хәзер читлектә тор,
Һәм бездән, кешеләрдән,
Бераз тәртипкә өйрән.

Ә мин сиңа өйрәтермен
Кызык-кызык һөнәрләр.
Тик сине тәмам әдәпкә
Өйрәтмичә җибәрмәм.

Икәү аңлаша башлагач,
Син бераз тәртипләнгәч,
Попугайлар кебек итеп
Сөйләшергә өйрәнгәч —
Мин дә сине тотып тормам,
Очыртырмын таллыкка.
Тик башкача беркемне дә
Интектермә, ялкытма.

АЛМА САТУЧЫ АПА ЯНЫНДА

Тротуарда бер апа
Кып-кызыл алма сата.
Карап торам аптырап,
Тезелгән озын чират:
Әбиләр дә бар монда,
Бабайлар да бар монда,
Малайлар да бар монда,
Маэмайлар да бар монда.
Песи дә бар чиратта,
Күсе дә бар чиратта.
Хәтта атлар да килгән
Ипподром дигән җирдән.
Ике маймыл басканнар
(Зоопарктан качканнар).
Күзлек кигән карт карга
Килеп басты иң алга...
Аптырама бу хәлгә,
Чынын әйтсәм әгәр дә —
Бу чиратны мин үзем дә
Күрүен һич күрмәдем,
Күрдем диеп болай гына,
Юри генә сөйләдем...
Тик чыннан да урамда
Шушындый чират торса,
Кызык булмас идемени
Кызык сөйгән кешегә?!
Ягъни минем ишегә,
Яки синең ишегә.

КУРАЙЛАР ХОРЫ

Әрәмәдән чуар көпшә
Җыеп алып кайттык та,
Ясадык без бик күп курай
Төрле-төрле тавышка.
Кайсы калын итеп, кайсы
Нечкә итеп сызгыра.
Җаен белсәң, барысы да
Матур көйләр сыздыра.
Авылдагы бөтен малай
Курайчы малай булды.
Кичләрен һәрбер урамга
Курай моңнары тулды.
Бер урамда яңгырап тора
Сандугачлар сайравы,
Ә берсеннән ишетелә
Карурманнар шаулавы.
Без бик күп көйләр өйрәндек,
Олылар тыңлап торды.
Әрәмәдә үскән икән
Моңлы курайлар хоры.

ШУШЫ ЯЗГЫ МИЗГЕЛДӘ

Тып-тып итеп
Тыпылдап,
Чылтыр-чылтыр
Чылтырап,
Биек йортлар түбәсеннән
Боз сөңгеләр коела.
Ялт-йолт итеп
Ялтырап,
Дерелдәп һәм
Калтырап,
Урамдагы гөрләвектә
Кояш нуры коена.
Чырык-чырык
Чыркылдап,
Очып йөри
Пырхылдап
Өй турында чыпчыклар.
Шушы язгы мизгелдә,
Карамыйча бернигә,
Өйдән чыгып чабар идем —
Әни кушкан эшем бар.

ГӨРЛӘВЕКЛӘР АРТЫННАН

Югарочтан түбәночка
Һәрбер урам чатыннан
Гөрләвекләр чыгып чаба
Гөрләвекләр артыннан.

Югарочтан түбәночка
Һәрбер урам чатыннан
Малай-шалай чыгып чаба
Гөрләвекләр артыннан.

КЫЧЫТКАН

Читән буен сарып алган
Куе яшел кычыткан.
Тик торганда өтеп алды —
Әллә кулы кычыткан.

БЕЗНЕҢ УРАМ КЫЗЫ

Ракетага атланып,
Дәртләнеп, канатланып,
Кычкырып көлә-көлә,
Тротуар буйлап килә
Космос кызы Лилия.

Космос кызы булмаса да,
Ул — безнең урам кызы.
Ракета итеп эшләнгән
Велосипед бүләк иткән
Аңа Рәшит абыйсы.

Ракета-велосипедка
Атланып, канатланып,
«Әй, юл бир!» — дия-дия
Тротуар буйлап килә
Кеп-кечкенә Лилия.

Кечкенә булса ни, тиздән
Ул үсеп җитәр әле.
Хәзер велосипед йөрткәч,
Ракета да йөртер үскәч —
Космоска китәр әле.





АТЛАС ҺӘМ «АТЛАНТ»

(Тел күнектергеч)

Аты атлап барганда да
Атлас аңа атлана.
Аның ап-ак яллы аты
«Атлант» диеп атала.
Атлас аңа атлана да
Китә атлар сакларга.
Барып җиткәч «Атлант»ны
да
Җибәрә ул утларга.
Атлар кырга таба чапса,
Атлас тагын атлана
Ап-ак яллы, ак тулпары
Акыллы ат — «Атлант»ка.
Атлас җилдәй җилеп бара,
«Атлант» уктай атыла.
Алты малай авыз ачып
Кызыгып карап тора.

ӘТӘЧЛӘРЕМ

Әтәчебезнең рәсемен
Ясап куйдым бер калайга.
Шундый матур килеп чыкты —
Шаккаттылар бар малайлар.
Аннары мин ул рәсемне
Иплəп кенә кисеп алдым.
Килеп чыкты калай әтәч —
Мин үзем дә хәйран калдым.
Үзебезнең чын әтәч тә
Бик ошатты минем эшне.
Озак кына карап торды
Һәм: «Кот-котыйк!» — дип эндәште.
Ләкин рәсемдәге әтәч
Аңа һич тә җавап бирми.
Тып-тын гына басып тора —
Ул шул әтәч телен белми.
Мин аны өй түбәсенә
Кадап куйдым, аптырагач.
«Флюгер булырсың,— дидем,—
Әтәч телен аңламагач».
Әле алга, әле артка,
Уңга, сулга әйләнде ул.
Шулай итеп, озакламый
Җилләр телен өйрәнде ул.

Тере әтәч хәбәр итсә
Таң атар вакыт җиткәнне —
Калай әтәч әйтеп тора
Кайсы яктан җил искәнне.

МИНЕМ ТЫРЫСЫМ

Кибеттән чиләк сатып ал диеп
Борчып тормадым әле әнине.
Каен тузыннан үрдем бер тырыс,
Ярдәмгә дәштем бары әбине.

Матур булсын дип бик тә тырыштым,
Күр, нинди күркәм булды тырысым.

Урманга баргач, алсу җиләкләр
Минем тырысны бик ошаттылар.
Мине өз, диеп, яфрак астыннан
Чыгып калырга ашыкты алар.

Мин җиләкләрне бик тә яратам,
Каен тырыска утыртып кайтам.

Ал җиләкләрне кызыктыруның
Бик ансат юлын уйлап таптым мин.
Каен тузыннан тырыс үрдем дә
Күп итеп җиләк җыеп кайттым мин.

Каен тырыста каен җиләге,
Көнләшеп калсын кибет чиләге.



ДҮРТ ӘТӘЧ

Юл өстендә тузан уйный —
Ике яшь әтәч талаша.
— Безнең әтәч җиңә,— ди-ди
Ике малай якалаша.

ГӨМБӘ ҖЫЯРГА БАРДЫМ

Гөмбә җыярга бардым,
Барып җиткәнче ардым.

Утырдым да бер төпкә
Карадым тирә-юньгә.

Менә сиңа табыш, ә-ә!
Тирә-ягымда гөмбә!
Ак гөмбә, майлы гөмбә,
Шампиньон һәм гөреҗдә.

Азапланмый-нитми генә
Гөмбә җыеп утырам.
Төп өстендә килеш кенә
Кәрзинемне тутырам...

Әнә шулай хыялланып,
Төрле-төрле уй корам.
Буш кәрзингә карый-карый
Төп башында утырам.

Гөмбә җыярга бардым,
Барып җиткәнче ардым.

ЯШЕНЛЕ ЯҢГЫР

Болыт килә үкереп,
Дөбер-дөбер иттереп.
Яшеннәрен уйната,
Шомлы уйлар уйлата.

Авыл турына җитә,
Яңгыр тетепме тетә!
Без почмакка посабыз,
Бер-беребезне кочабыз.

Яшен гөлт итеп куя,
Йөрәк дерт итеп куя.
Күк күкри дөбердәп,
Без ятабыз дерелдәп.

Сөйләшәбез тын гына,
Тын гына, мыштым гына:
«Яңгыр бер узып китәр,
Болыт таралып бетәр.

Менә инде шул чакта
Без дә җаен табарбыз,
Күк күкрәгән кебек итеп
Дөбер-шатыр чабарбыз!»

ҖЕН ТҮГЕЛ

Шаяра, сикерә, пырхылдый, шаркылдый.
Бу — минем абыем Шатгали шуклана.
Әбием аптырый, тәртипкә чакыра,
Аннары зарлана, аннары сукрана:

«Нишләде бу малай, ни булды соң моңа?..
Шуклана да тора, шуклана да тора...
Адәм зат болай ук кыланмас иде лә,
Мөгаен, эчендә усал җен утыра».

Мин әйтәм: «Әбием, мин белдем, төшендем,
Минемчә, бу эшнең сәбәбе бик гади —
Шук кеше шат була, димәк ки, җен түгел,
Шатгали эчендә утыра Шукгали».

ЮРИ ГЕНӘ

Икеле алгач: «Мин юри
Укымадым,— ди,— өйдә».
Янәсе, ул юри генә
Ала икеләне дә.
Аяк киемен дә юмый,
Мәктәпкә килгән чакта.
— Юри генә юмадым ла,
Шаккатмагыз! — ди Гата.

Ни әйтергә дә белмибез,
Аптырыйбыз, йөдибез.
— Дөрес эшләмисең, Гата,
Син — кире малай,— дибез.

Беркөнне ул бишле алды,
Ләкин сер бирми генә:
— Юри укыдым. Бишлене
Алдым,— ди,— юри генә.
Аяк киемен дә юган.
Бөтен кеше шакката.
— Аю күрдегезме әллә,
Юри юдым,— ди Гата.

Ни әйтергә дә белмибез,
Аптырыйбыз, йөдибез...
Аннан дәррәү: «Юри генә
Син гел шулай йөр!» — дибез.